## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино урта гомуми белем бирү мәктәбенең




**югары квалификация категорияле**
**татар теле һәм әдәбияты**
**укытучысы**

# Зиннәтова Гүзәл Илалетдин кызы

# **Мастер-класс.**

*Укытучы:* ***Зиннәтова Гүзәл Илалетдин кызы***

*Фән:* ***Татар теле.***

*Класс:* ***6 (татар мәктәбе)***

*Тема:* ***Үткән заман хикәя фигыльнең төрләре.***



Су – Ходай биргән зур байлык.



Бик күптән бу авылда бик бай кеше яшәгән. Аның йорт-җирләре матурлыгы белән тирә-якта дан тоткан. Ишегалдында гына коесы да булган.



Көннәрнең бер көнендә бу йорт янына бер мосафир туктаган.

Ул бик йөдәгән, аның хәле беткән.

Хуҗадан эчәргә сораган. Тик бай  су бирмәгән.



Юлчы китеп барган. Шуннан соң кинәт зур давыл купкан, чиләкләп яңгыр койган...



**Көн аязганда, йорт урынында бары тигез җир калган.**

**Теге байны да башка күрүче булмаган.**








Мин бер бай йорты янына кил...



Хуҗадан эчәргә су сора... . Ул бирмә...



Мин китеп бар... .
Давыл күтәрел..., яңгыр коя башла...



Бераздан көн аяз... .
Йорт урынында тигез җир кал...

# Үткән заман хикәя фигыльнең төрләре

| | |
|---|---|
| **Билгеле үткән заман** | **Билгесез үткән заман** |
| Үзе күргән яки аңа билгеле эш-хәл турында сөйләгәндә | Үзе күрмәгән яки үтәлүен сизмәгән эш-хәл турында сөйләгәндә |
| **-ды/-де, -ты/ -те** | **-ган/гән, -кан/-кән** |

# *Үткән заман хикәя фигыльнең төрләре*

*Билгеле* (*ле*)
*үткән заман*

*Билгесез* (*сез*)
*үткән заман*



Су – Ходай биргән  зур дәүләт ул!